КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 октябрь г.Казань № 1137

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1368 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары» сүзләрен «әйләнә-тирә мохит» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе идарәсе бүлегенең төп консультантлары, өлкән белгечләре, Министрлыкның территориаль идарәләрендәге консультантлары, 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре, 1 разрядлы белгечләре, Министрлыкның Үзәк территориаль идарәсенә караган махсуслаштырылган инспекциянең башлыгы, башлык урынбасары, баш белгечләре, төп белгечләре, Министрлыкның территориаль идарәләрендәге экология күзәтчелеген тәэмин итү бүлеге белгечләре – әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары.»;

2.2 пунктта «инспекция визиты, рейд тикшерүе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Министрлыкта мәҗбүри таләпләрне бозарга җыену яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмә булган очракта һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салган (зарар китергән) йә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян салу (зарар китерү) куркынычын тудырган дип расланган мәгълүмат булмаган очракта, Министрлык контрольдә тотылучы затка карата мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү белдерә һәм аңа мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итә.»;

4.8 пунктның бишенче абзацында «сынау, инструменталь тикшерү» сүзләрен өстәргә;

4.10 пунктта «әйләнә-тирә мохитне саклау» сүзләрен «җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау» сүзләренә алмаштырырга;

VI бүлектә:

беренче абзацка «2024 ел – 53 берәмлек» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин